| | | |
|---|---|---|
| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>ШӘҺӘР СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2025 ел № 2/10

Шәһәр Советының аерым карарларына
үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2019 елның 26 декабрендәге 35/5 номерлы Карары белән расланган 2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль күчемсез милек исемлегеннән 16:52:070103:2798 кадастр номерлы гаражны һәм 16:52:070103:102, 16:52:070103:103 кадастр номерлы җир участокларын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.
2. Шәһәр Советының 2021 елның 3 ноябрендәге 9/17 номерлы Карары белән расланган 2022 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль күчемсез милек исемлегеннән 16:52:020701:179 кадастр 91 а/м исәпләнгән җир асты гаражын һәм 16:52:040301:8423 кадастр номерлы җир участогын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.
3. Шәһәр Советының 2022 елның 8 декабрендәге 18/10 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2023 елның 29 мартындагы 22/11, 2023 елның 25 октябрендәге 27/10 номерлы Карарлары редакциясендә) 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) хосусыйлаштыру планлаштырыла торган муниципаль күчемсез милек исемлегеннән 16:52:100402:114 кадастр номерлы 60% әзерлектәге төгәлләнмәгән төзелеш объектын, 16:52:100402:100 кадастр номерлы җир участогын төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.
4. Шәһәр Советының 2023 елның 6 декабрендәге 28/11 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2024 елның 4 мартындагы 32/9 номерлы

Карары редакциясендә) 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) Яр Чаллы шәһәренең үзгәртеп кору планлаштырыла торган муниципаль предприятиеләре исемлегеннән «Шәһәр коммуналь хуалыгы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль унитар предприятиесен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

5. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев